ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2006 елның 28 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4; 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына шәһәр яны юлларында халыкка автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш) транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләре бирелә.”;

2) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Шәһәр яны юлларында халыкка автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш) транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнарына бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 20 нче числосына кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвеш буенча бирелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 9 июле
№ 59-ТРЗ